Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

12 март 2020 ел № 189

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2013 елның 15 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында»гы 116 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАРЫ БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2013 елның 15 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында»гы 116 нчы номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советеның 2014 елның 2 октябрендәге 141 нче номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 151 нче номерлы, 2015 елның 6 маендагы 179 нчы номерлы, 2015 елның 20 ноябрендәге 13 нче номерлы, 2016 елның 8 ноябрендәге 49 нчы номерлы, 2018 елның 31 маендагы 122 нче номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 126 нчы номерлы, 2019 елның 28 августындагы 166 нчы номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-« -торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент мөнәсәбәтендә (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш»;

1.2. 5 пунктны төшереп калдырырга;

1.3. 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1.1, 1.3 пунктлары рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай узгач үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. Әлеге карарның 1.2 пункты 2021 елның 1 гыйнвареннән,

әмма рәсми басылып чыккан көненнән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хәмидуллин Ф.Р.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов